Котлы-Бөкәш авыл җирлеге башкарма комитеты
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

КАРАР № 9

Котлы-Бөкәш авылы 2016 елның 15 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы-Бөкәш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы-Бөкәш авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында»2015 елның 20 июлендәге 39 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнар белән тәңгәлләштерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты, 3,4 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3,5 өлеше нигезендә, муниципаль норматив хокукый актны законнарга яраклаштыру максатларында, авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертү, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының « Котлы-Бөкәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы-Бөкәш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы-Бөкәш авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» 2015 елның 20 июлендәге 39 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга : Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт; Мәмле Казаклар Чаллысы авылы, Үзәк урам, 29 йорт; Сатлыган авылы, Ленин урамы, 25а йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге башлыгы Г.Г. Нәҗипов